СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 150 13.06.2017

№ ________ от _________________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2011 елның 15 ноябрендәге 76 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Бирелгән вәкаләтләр кысаларында Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турында” 2011 елның 12 августындагы 660 номерлы карарының 2 пункты нигезендә һәм “Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 30 декабрендәге 431-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибен раслау турында» 2011 елның 15 ноябрендәге 76 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– Тәртипнең 3 пунктындагы 3 пунктчасында «һәм геодезик билгеләр» сүзләрен «дәүләт геодезик челтәрләренең билгеләре, геодезик пунктлары, гравиметрик пунктлар, нивелирлы пунктлар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов